**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Советская, д. 81, Азнакаевский район,
с.Чубар-Абдуллово, 423323,
тел./факс (885592)38-7-37
E-mail: Chabd.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Советская ур., 81 йорт, Азнакай районы, Чубар-Абдул авылы, 423323
тел./факс (885592)44-5-21
E-mail: Chabd.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «02» апреля 2025 г.** **№ 16**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз терлекләрнең элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз терлекләрне кире кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге һәм терлекләрне хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Терлекләр белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терлекләрне хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башлыгы хуҗасыз терлекләрнең элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз терлекләрне кире кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле зат булып тора.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. урнаштырырга:

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Н.А. Фатхетдинов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына кушымта
«02» апреля № 16

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терлекләрне хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

1. Балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары (мәктәпләр, балалар бакчалары) һәм сәламәтлек саклау оешмалары, социаль өлкә учреждениеләре территорияләре һәм күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният объектлары янындагы территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары.

6. Йорт хайваннарын йөртү, көтүлек һәм авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларны йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

7. Индивидуаль торак төзелеше булган йортларга, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар урнашкан күпфатирлы йортлар янәшәсендәге территорияләр һәм әлеге территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковка (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юлларын кертеп, күпфатирлы йортларга якын юлларны да кертеп, әлеге территорияләрне төзекләндерү элементлары булган территорияләр.

8. Зиратлар.